# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Лебяжье авыл җирлеге Лебяжье торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**2023 елның 13 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 12.10.2023, 13.10.2023 тә узган гражданнар җыеннарының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2024 елда Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендәге Лебяжье торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,тыл хезмәтчәннәреннән,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) урамнарны яктыртуны карап тоту;
2) юлларны карап тоту һәм төзү;
3) су белән тәэмин итүне карап тоту;
4) территорияне төзекләндерү;
5) ККК мәйданчыкларын карап тоту».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 831 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 424 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 416 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 8 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлегендәге Лебяжье авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карары кабул ителгән дип танырга: «Сез 2024 елда Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендәге Лебяжье авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә

укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) урамнарны яктыртуны карап тоту;

2) юлларны карап тоту һәм төзү;

3) су белән тәэмин итүне карап тоту;

4) территорияне төзекләндерү;

5) ККК мәйданчыкларын карап тоту».

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Лебяжье авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Лебяжье авыл җирлеге башлыгы Д.Ә.Гыйләҗев